

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2008

Мәктәптә укулар бетү белән, 7 нче «б» сыйныфы укучылары Казан Кремленә экскурсиягә баралар. Моны класс җитәкчеләре — Гөлсинә апалары оештыра. Укучылар, герой-шагыйрь Муса Җәлил һәйкәленә чәчәкләр куеп, көрәшчебезгә тирән ихтирамнарын белдергәч, Кремль капкасына таба юнәләләр. Сыйныфта шуграк саналган Динар «ботаник» Гаделне җиңеннән тартып туктата:
Тукта әле, сиңа сүз бар иде!
Юк, сукма, ми...
Миңа әти сөйләгән иде, Кремль астында яшерен юллар бар, дип, аларга диварлар астыннан керергә була, ди. Тагын әти: «Анда төшеп карамаган малай чын егет була алмый», — диде.
Без кечкенә чакта Кремль диварлары аша җир астыннан йөри идек. Ләкин син, малай, кара аны, төшеп йөри күрмә! Тәртип бозасы булма!

Малайлар казу эшләре барган урынга килеп җитәләр.
Әйдә, мин синнән дә чын егет ясыйм, өй эшләрен дә кучерергә бирә башлар идең!
Төшке ашка киттек, БОРЧЫМАСКА!
Динар кечкенә генә ишек күрә. Тоткасын тартып карый, әмма ишек ачылмый...
Төшке ашка киттек, БОРЧЫМАСКА!
Бу вакытта ике археолог төшке аштан кайталар.
Менә күрерсең, без зур ачыш алдында торабыз, минем исәпләүләрем буенча, кайдадыр бу тирәдә вакыт җепләренең кисешү урыны — «тылсымлы портал» булырга тиеш.
Төшке ашка киттек, БОРЧЫМАСКА!
Әптчи!

Анда кемдер бар, чит кеше кергән, ашыгырга кирәк!
Чын егет буласың килсә, сикер, югыйсә штраф түләтәчәкләр.
Шарт!
Гөрс!
Син мине әллә кая алып төштең. Минем кайтасым килә.
Мескенләнмә, чын егетләр еламыйлар... Кара әле, диварда ниндидер язу!

Гарәп хәрефләре белән язылган. Гарәпчә укырга мине дәү әни өйрәткән иде... Коръән дә шул хәрефләр белән язылган.
Нәрсә дип язылган, укы тизрәк. Мин дәү әни сүзен тыңламыйм шул, көне буе сәпиттә чабам, футбол уйныйм.
Киттек, монда ятып булмас, факеллар янып беткәнче ашыгыйк.
«Бу юл-дан ба-ру-чы-лар зур сы-нау-лар ү-тә-чәк. Әйләнеп кайтыр өчен, көчсез кеше — көчле, куркак — батыр, белемсез зирәк һәм белемле булырга тиеш.
Метро поезды үтеп китте, ахры.
Кара, әнә тегендә нәрсә ул?..
Малайлар түгәрәк формасындагы җир асты мәгарәсенә килеп чыгалар. Уртада таштан эшләнгән зур цилиндр күрәләр...


Болары — латин графикасындагы вакыт төере, болары — гарәп графикасында, ә болары...
Болары да шундый ук язу дип уйлыйм. Бары рун хәрефләре белән генә бирелгән. Әти сөйләгән иде аны: безнең бабаларыбыз төркиләр, аларның язулары шундый булган, дип.
Мин сине белемсез, надан дип уйлаган идем, өметсез түгелсең икән.
Кара аны, егет булдым дигәч тә, теләңә салынма!
Өстендә ниндидер асылташ бар, тузанын сөртеп карыйм әле.
Гаделнең кулы асылташка тиюгә, мәгарәнең эче кинәт үзгәрә. Диварларда хәрабәләр сурәте, сугыш вакыйгалары пәйда була.
Бу бит Рейхстаг, минем аны киноларда күргәнем бар.

Рейхстагка беренче булып җиңү әләмен куйган батыр сугышчы Гази Заһитовка у-ур-ра-а-а!
Шул мизгелдә мәгарә эче тоныкланып кала.
Ә безнең тарих дәреслегендә никтер беренче булып Рейхстагка рус кешесе аяк баскан дип язылган.
Әти әйтә, дөреслекне кеше үзе эзләп табарга тиеш, ди...

Ә хәзер минем чират.
Мәгарәдә кинәт түгәрәк чоңгыл барлыкка килә һәм малайларны үз эченә суырып ала.
Ой-ой!!
Гадел белән Динар ниндидер коридорга килеп эләгәләр. Өс киемнәре үзгәргән. Гадел хәрбиләр киемендә, Динар елъязмачы кыяфәтендә.
Әй, кем бар анда?
Без Казан мәктәбеннән, 7 нче «б» малайлары!

Сез казанлыларга охшамаган, безнең серләрне белергә җибәрелгән шымчылардыр әле?!
Без тарих музеена эләккәнбез, ахры, билет ничә сум тора?
Казан кешеләре икәнлегегезне исбатлагыз, юкса җәза күрәчәксез!
Без... без Колшәрифне беләбез.
Кем ул?
Ул... ул...
Ул — шагыйрь, ул — сәет!..
Аның сәет икәнлеген кем дә белә. Сәет кем соң ул?
Сәет — Мөхәммәт пәйгамбәр нәселенә тоташкан кеше, Колшәриф — Казан ханлыгының сәете, дини юлбашчысы.


Кинәт ишек ачыла. Кылыч тоткан Урта гасыр сугышчысы малайларны җилтерәтеп алып керә һәм, ишекне шапылдатып ябып та куя.
Руслар яу килергә торганда, йөзегезгә кяфер кыяфәте чыгарып, телегезгә салынып нишләп йөрисез, малай актыклары?
Барыгыз, коралланып, туган җирегезне сакларга әзерләнегез!
Малайлар яңа төзелгән агач манара янына килеп җиткәннәрен сизми дә калалар.
Без музейда түгел икән бит, Гадел...

Кинәт кемдер Динарны үз янына чакырып ала.

Динар үзенең гарәп хәрефләре белән яза башлавын сизми дә кала.


Күпмедер вакыттан соң...
Аһ-һ!.. Сөембикә үзе бит бу?!
Ханбикә килә, ханбикә!


Шулчак манара эченнән рус яугирләре һәм боярлар килеп чыга.
По условиям вашей царицы с нашим государем-батюшкой, мы ее забираем!
Ханбикәне урлыйлар, аны коткарырга кирәк!..

Ханбикә, әйдәгез манарага! Тизрәк!..
Халык Сөембикәне рус яугирләреннән аралап алырга тели.
Бәйлә аларны... Алар ханбикәне алып китмәкче булалар...



Манараның өске катында Сөембикә күренә.
Мин үз дәүләтемне ташлап китмим, үлсәм дә, туган җиремдә калам.
Динар белән Гадел Сөембикәне тотып калырга тырышалар...
Тәрәзә артында һава чоңгылы барлыкка килә һәм ханбикә белән малайларны үз эченә суырып ала.
ОЙ!
А-А-А!!!



УДК 821.512.145-3-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ж17

Җамал А.М.

Ж17 Гадел һәм Динар маҗаралары, яки Сөембикәдә кунакта: комикс/Айдар Җамал. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 16 б. — 3000 д. — ISBN 978-5-298-01740-4

УДК 821.512.145-3-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4

Литературно-художественное издание
Для детей младшего и среднего школьного возраста

Джамал Айдар
(**Замалиев** Айдар Маратович)

Приключения Аделя и Динара, или В гостях у Сююмбеки

Казань. Татарское книжное издательство. 2008
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма
Кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары өчен

Җамал Айдар
(**Җамалиев** Айдар Марат улы)

Гадел һәм Динар маҗаралары, яки Сөембикәдә кунакта

Мөхәррире *Л.М.Шәехов*. Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*. Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.Н.Мусина*. Корректоры *Г.М.Хәбибуллина*. Оригинал-макеттан басарга кул куелды 20.11.2008. Форматы 70×108 1/16. Шартлы басма табагы 1,4. Тиражы 3000 д. Заказ Т-1525. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. **http://tatkniga.ru. e-mail: tki@tatkniga.ru.**
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ISBN 978-5-298-01740-4

© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Җамал А.М., 2008